ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.11.2020 с.Старое Дрожжаное № 645

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Мочәли башлангыч мәктәбе-Советлар Союзы герое Нурулла Гарифулла улы Фазлыев исемендәге балалар бакчасы "мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 37 статьяларына, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 14 августындагы 408 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советлар Союзы герое Нурулла Гарифулла улы Фазлыев исемендәге Мочәли башлангыч мәктәп-балалар бакчасы» Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктны киләсе яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Белем бирү эшчәнлеге Россия Федерациясе дәүләт телендә алып барыла.

Россия Федерациясе гражданнары Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган телдә башлангыч гомуми һәм төп гомуми белем алуга, шулай ук мәгариф системасы бирә торган мөмкинлекләр чикләрендә Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган телне өйрәнү хокукына ия. Россия Федерациясе халыклары телләре, шул исәптән рус теле буларак, дәүләт аккредитациясе алган белем бирү программалары кысаларында туган телне укыту һәм өйрәнү федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

1.10 пунктны киләсе яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.10. Укучыларның туклануын оештыру белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы МББУГА йөкләнә һәм укучыларның туклануын оештыру турындагы нигезләмә белән көйләнә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.